**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

---

**2021елның 27 гыйнвары** **1 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә карар бирәм**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегендә, 1, 2 кушымталар нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлеге Башкарма комитетының « 2021 елга җирләү буенча гарантияле хезмәтләр күрсәтү исемлеге тарифын раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 4 номерлы карары 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo/tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Н.И.Миннуллина**

*2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы*
*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль*
*районының Матюшино авыл җирлеге*
*Башкарма комитеы*
*карарына 1 кушымта*

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны җиткерү | 4 118,10 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 986,58 |
| 4. Җирләү (кабер казу, күмү) | 1 860,00 |
| **Барлыгы** | **6 964,68** |

*2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы*
*Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль*
*районының Матюшино авыл җирлеге*
*Башкарма комитеы*
*карарына 2кушымта*

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Матюшино авыл җирлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе ( сум.) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 428,40 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм кирәкле башка предметларны җиткерү | 3 689,70 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 986,58 |
| 5. Җирләү (каберне казу һәм күмү) | 1860,00 |
| **Барлыгы** | **6 964,68** |